Казан шәһәре Мәскәү районы
Фатиха Аитова исемендәге
татар телендә белем бирүче
12 нче гимназиясе

# Халык язучысы, күренекле драматург, җәмәгать эшлеклесе
# ТУФАН МИҢНУЛЛИН ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАНГАН МЕМОРИАЛЬ ЗАЛ
## *(әдәби-иҗади кунак студиясе)*


КАЗАН
2013-2015



## ТУФАН МИҢНУЛЛИН ВАСЫЯТЬЛӘРЕ:


***Татар кешесе!***

***Укы! Гыйлемле-белемле бул! Дәүләт төзү, аның белән идарә итү өчен дә, рухи һәм матди байлык туплау өчен дә аң-белем кирәк... “Укып мулла булмассың, чукып карга булмассың” дигән мәкаль бүген аеруча зарарлы. Моны яшьләребез белергә тиеш. Кушканны гына эшләүчеләрнең киләчәге юк. Һәр эшнең, һәр хезмәтнең нигезендә иҗат ята...***



| | |
|---|---|
| Музейның исеме | Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган мемориаль зал |
| Гамәлгә куючы | Казан шәһәре Мәскәү районы Ф.Г. Аитова исемендәге 12 нче гимназиясе |
| Юридик һәм фактик адресы | Декабристлар ур., 89А, Казан ш., Татарстан Республикасы, 420034 |
| Элемтә телефоны | ☎ 8(843) 562-20-39 Факс: 8(843) 562-25-43 |
| Директор | Темиркәева Илһамия Абделхәй кызы |
| Музей житәкчесе | Атряскина Хава Фатыйх кызы |
| E-mail | G12tat.kzn@tatar.ru, Tg-12@mail.ru |
| Сайт | https://edu.tatar.ru/moskow/page2218.htm/page2679502.htm |
| Электрон картотека | Z:\Педагог-организатор\Музей Туфан документы |

# Туфан абый теләкләре






# ТЕМАТИК-ЭКСПОЗИЦИЯ ПЛАНЫ

*Кеше белән язылмаган законнар*
*идарә итәргә тиеш, аның эчке дөньясы,*
*аның рухы.*

*Туфан Миңнуллин*

***Туфан Миңнуллинга багышланган мемориаль зал*** Казан хакимиятенең матди ярдәме белән 2013 нче елның 1 нче мартында ачылды. Күренекле шәхеснең “Хәтер залы” аны күпьяклы талант иясе буларак ачып бирә. Югары зәвык, заманча бизәлеш белән эшләнгән экспозиция үзәгендә – тукталган мизгелләр - фотосурәтләр... Аларда Туфан ага бала да, горур “щепкинчы” да, сөекле ир солтаны да, кайгыртучан әти, бабай да, туры сүзле депутат та, танылган язучы да. Үзе исән чакта бакчасында иҗат иткән агач өстәле зал түренә сыенган. Өстәлдә исә минус 34ле калын күзлеге, кулъязмалары, бастыру машинасы, каурый каләмнәре...

Туфан рухы белән сугарылган “Хәтер залы”на аның якташлары, фикердәшләре, театр әһелләре, гаиләсе һәрчак кунакка килеп тора. Бу зал гимназия укучыларының иҗат бүлмәсенә әверелде. Биредә уңышлы гына гидлар төркеме эшләп килә.

2013 нче елның ноябрендә ***укучы кызларның “Хәят” әдәби-иҗади клубы*** оешты. Туфан аганың “Хәтер залы”нда “бөреләнгән” кызлар клубы әкренләп укучылар үзидарәсен, 2013-2014 елларга эш планын булдырды. Әлеге клубның беренче кунагы – халык язучысы Нурихан Фәттахның тормыш иптәше – табибә Руфина ханым Фәттахова булды. Нигездә, гамьле әңгәмә Туфан Миңнуллинның “Хәтер залы”нда башланып, татар теле һәм әдәбияты бүлмәсендә “Түгәрәк өстәл” артында төгәлләнә. Үзәктә – замана кызларын борчыган мәсьәләләр, тәҗрибәле шәхестән киңәш-табыш, үз иҗатың белән таныштыру, фикерләшү һ.б.


ГИМНАЗИЯ БИНАСЫ
ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КЛАССИГЫ,
КҮРЕНЕКЛЕ ДРАМАТУРГ
ТУФАН ГАБДУЛЛА УЛЫ
МИҢНУЛЛИННЫҢ
ЗУР ЯРДӘМЕ
БЕЛӘН САЛЫНДЫ
ЗДАНИЕ ГИМНАЗИИ
ПОСТРОЕНО ПРИ
ДЕЯТЕЛЬНОМ УЧАСТИИ
КЛАССИКА
ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ,
ВЫДАЮЩЕГОСЯ ДРАМАТУРГА
ТУФАНА АБДУЛЛОВИЧА
МИННУЛЛИНА











**Туфан абый дәресләре...**













**Туфан Миңнуллинга багышланган мемориаль зал**

**каршысында оешкан**

**“Хәят” әдәби-иҗади клубының**

**2013-2014 нче уку елына эш планы**

*Азга канәгать булган халык*
*бөек эшләр эшли алмый.*
*Туфан Миңнуллин*

| Үткәрү вакыты | Әңгәмә темасы | Чакырылган кунакның исеме, фамилиясе; вазифасы | Катнашучылар |
|---|---|---|---|
| ***Ноябрь*** | “Халык язучысы Нурихан Фәттахның гаилә серләре” | *Руфина Фәттахова, Н.Фәттахның хатыны, күренекле табибә* | И.А.Темиркәева, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 5-10 нчы сыйныф |
| ***Декабрь*** | “Татарның бер баласы”/ Туфан Миңнуллин якташлары белән очрашу | *Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа, Олы Салтык мәктәпләреннән килгән укучылар һәм укытучылар, әдипнең туганнары* | И.А.Темиркәева, З.К. Латыйпова, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 8-10 нчы сыйныф |
| ***Январь*** | “Гаилә – милләт нигезе”/ ТР Фәннәр Академиясенең Гаилә һәм демография фәнни-тикшеренү үзәге | *Флюра Илдарханова, Альта Мәхмутова, Лилия Байбулатова, Роза Вәлиева; галимәләр* | И.А.Темиркәева, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 5-10 нчы сыйныф, эти-әниләр комитеты |
| ***Февраль*** | “Кытай татарлары Ана телен гаиләдә саклый”/ Ак калфак” бөтендөнья татар хатын-кызлары оешмасы рәисе Кадрия Рәис кызы Идрисова белән очрашу | *Кадрия Идрисова; филология фәннәре кандидаты, “Ак калфак” оешмасы рәисе; Кытай татарлары* | И.А.Темиркәева, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 3-10 нчы сыйныф, эти-әниләр комитеты |
| ***Март*** | “Мәшһүр хатын-кызлар”/ Тәэминә Биктимерова белән өчрашу | *Тәэминә Биктимерова; тарих фәннәре кандидаты* | И.А.Темиркәева, Х.Ф.Атеряскина, Н.В.Сәлахова, Р.Н.Рәхмәтуллина, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Р.Т.Хуҗина,<br>Р.Г.Газизуллина,<br>3-10 нчы сыйныф |
| ***Апрель*** | “Тукай эзләре буйлап Кытай һәм Казакъстан илләренә беренче журналистлар экспедициясе нәтиҗәләре”/ Г.Тукайның мирасын саклау һәм үстерү Фонды” президенты, Г.Тукайның дүртенче буын туганы, журналист Риман Гыйлемханов белән очрашу | *Риман Гыйлемханов; Тукай Фонды президенты, журналист* | И.А.Темиркәева,<br>Р.Н.Рәхмәтуллина,<br>Р.Т.Хуҗина,<br>Р.Г.Газизуллина,<br>1-10 нчы сыйныф |
| ***Май*** | “Фатиха Аитованың кызларны тәрбияләү үзенчәлекләре һәм алымнары”/ Фатиха Аитованың оныгы Булат Йосыф улы Аитов белән гамьле әңгәмә | *Булат Аитов; Ф.Аитованың оныгы, археолог; Альта Мәхмүтова, Ләйсән Кариева,Тәэминә Биктимерова; галимәләр* | И.А.Темиркәева,<br>Х.Ф.Атеряскина,<br>Н.В.Сәлахова,<br>Р.Н.Рәхмәтуллина,<br>Р.Т.Хуҗина,<br>Р.Г.Газизуллина,<br>5-10 нчы сыйныф |










**“Хәят” әдәби-иҗади клубының**

**2014-2015 нче уку елына эш планы**

## АКТУАЛЬ ӘҢГӘМӘЛӘР

| Үткәрү вакыты | Әңгәмә темасы | Чакырылган кунакның исеме, фамилиясе; вазифасы | Катнашучылар |
|---|---|---|---|
| ***Сентябрь*** | “Татар кешесе! Гыйлемле, белемле бул!”/ Мәдәният елына багышланган Белем көне тамашасы | *Нәҗибә Ихсанова, Әлфия Юнысова-Миңнуллина; Т.Миңнуллинның хатыны, кызы* | И.А.Темиркәева, Х.Ф.Атряскина, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 1-11 нче сыйныф, эти-әниләр |
| ***Октябрь*** | “Көләсе килеп тора”/ Балалар шагыйре, ТР Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан белән очрашу | *Рафис Харис улы Корбанов; шагыйрь, ТР Язучылар берлеге рәисе* | И.А.Темиркәева, Х.Ф.Атряскина, Г.З.Насыйбуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 1-5 нче сыйныф |
| ***Ноябрь*** | “Парламент дәресе”/ ТР Дәүләт Советы депутаты, шагыйрь Разил Вәлиев белән очрашу | *Разил Исмәгыйль улы Вәлиев; шагыйрь, ТР Дәүләт Советы рәисе, Туфан аганың дусты* | И.А.Темиркәева, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 5-11 нче сыйныф, сыйныф җитәкчеләре |
| ***Декабрь*** | “Татарча рок”/ “Иттифакъ” төркеме җырчысы, гитарист Альберт Исмаил белән очрашу | *Альберт Исмаил; танылган гитарист, композитор, рок җырчы* | И.А.Темиркәева, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 7-11 нче сыйныф |
| ***Февраль*** | “Сүз эчендә хикмәт бар”/ Фоат Галимуллин белән Туган тел көненә багышланган очрашу | *Фоат Галимуллин; филология фәннәре докторы, күренекле галим, тәнкыйтьче, диктор һәм җәмәгать эшлеклесе* | И.А.Темиркәева, Х.Ф.Атряскина, Н.В.Сәлахова, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 5-11 нче сыйныф |
| ***Март*** | “Туфан бит ул...”/ Халыкара театр көнендә Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган | *Галимнәр: Әлфәт Закирҗанов, Нурфия Йосыпова, Алсу Гайнуллина, Таһир* | И.А.Темиркәева, Х.Ф.Атряскина, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | II республика конференциясе җиңүчеләре һәм жюри әгъзалары белән очрашу | *Гыйләҗев; журналистлар: Васил Гарифуллин, Эльмира Закирова; артистлар: Нәҗибә Ихсанова, Фәнис Җиһанша, Алмаз Сабирҗанов һ.б.* | Р.Г.Газизуллина, Конференция җиңүчеләре |
| ***Апрель*** | “Шагыйрьлек – ул көрәш...” (Т.Миңнуллин)/ Йолдыз Шәрапова белән гамьле әңгәмә | *Йолдыз Шәрапова; шагыйрә* | И.А.Темиркәева, Х.Ф.Атряскина, Н.В.Сәлахова, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 5-7 нче сыйныф |
| ***Май*** | “Моңлы бер җыр”/ Гимназиянең сугыш ветераннары белән очрашу | *Сугыш ветераннары Ф.Галиев, И.Әбүбәкеров, Т.Федорова, Т.Газиев* | И.А.Темиркәева, Х.Ф.Атряскина, Н.В.Сәлахова, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 5-10 нчы сыйныф |









**“Хәят” әдәби-иҗади клубының**

**2015-2016 нчы уку елына эш планы**

**ТУФАН МИҢНУЛЛИНГА – 80!**

| Үткәрү вакыты | Очрашулар исемлеге | Чакырылган кунакның исеме, фамилиясе; вазифасы | Катнашучылар |
|---|---|---|---|
| ***Сентябрь*** | Туфан Миңнуллин тууына 80 ел тулуга багышланган Белем көне тамашасы Программада: Г.Камал театры артистлары катнашында “Авыл эте Акбай” спектакленнан өзек | *Нәҗибә Ихсанова, Әлфия Юнысова-Миңнуллина; Т.Миңнуллинның хатыны, кызы; Г.Камал театры артистлары* | И.А.Темиркәева, Х.Ф.Атряскина, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 1-11 нче сыйныф, эти-әниләр, гимназия коллективы |
| ***Октябрь*** | “Әкият” татар дәүләт курчак театры артистлары белән очрашу / мастер-класс | *Театр режиссеры Илдус Зиннуров җитәкчелегендәге артистлар төркеме* | И.А.Темиркәева, Х.Ф.Атряскина, Г.З.Насыйбуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 1-5 нче сыйныф |
| ***Ноябрь*** | “Сәхнәдә – 10 ел” / Автор-башкаручы Илназ Сафиуллин белән очрашу | *Илназ Зиннур улы Сафиуллин, автор-башкаручы* | И.А.Темиркәева, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 5-11 нче сыйныф, сыйныф җитәкчеләре |
| ***Декабрь*** | Язучы Нәбирә Гыйматдинова белән очрашу | *Нәбирә Гыйматдинова, язучы; “Идел” редакциясе журналистлары* | И.А.Темиркәева, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 7-11 нче сыйныф |
| ***Февраль*** | Галим Рафаэль Хәкимов белән очрашу | *Рафаэль Сибгат улы Хәкимов; Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты директоры, сәясәтче, тарих фәннәре докторы* | И.А.Темиркәева, Х.Ф.Атряскина, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 8-11 нче сыйныф |
| ***Март*** | “Без – Туфан | *Галимнәр: Әлфәт* | И.А.Темиркәева, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | варислары”/ Халыкара театр көнендә Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган III республика конференциясе җиңүчеләре һәм жюри әгъзалары белән очрашу | *Закирҗанов, Нурфия Йосыпова, Алсу Гайнуллина, Таһир Гыйләҗев; журналистлар: Васил Гарифуллин, Эльмира Закирова; артистлар: Нәҗибә Ихсанова,Ирек Баһманов, Әзһәр Шакиров һ.б.* | Х.Ф.Атряскина, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, Конференция җиңүчеләре |
| ***Апрель*** | “Батулла дәресләре”/ Рабит Батулла белән очрашу | *Рабит Батулла; язучы* | И.А.Темиркәева, Х.Ф.Атряскина, Г.З.Насыйбуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 5-7 нче сыйныф |
| ***Май*** | Бөек Ватан сугышы музее директоры Михаил Черепанов белән очрашу | *М.В. Черепанов, Бөек Ватан сугышы музее директоры* | И.А.Темиркәева, Х.Ф.Атряскина, Р.Н.Рәхмәтуллина, Р.Т.Хуҗина, Р.Г.Газизуллина, 5-10 нчы сыйныф |







## ТУФАН МИРАСЫН ӨЙРӘНҮ

## ДӘВАМ ИТӘ

Гимназиядә Туфан Габдулла улы Миңнуллин хезмәтләрен, эш алымнарын, тормыш тәҗрибәләрен өйрәнүгә зур урын бирелә. Олуг шәхеснең тормыш юлын, милли мәгариф юлындагы эшчәнлеген өйрәнеп, аның күркәм традицияләрен дәвам иттерү – кызларга милли тәрбия бирүдә гимназия үз алдына куйган мөһим бурычларның берсе. Гимназия канаты астында оешкан “Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган мемориаль зал” укучыларны фәнни-иҗади эзләнүләргә илһамландырып тора.

Гимназиядә Туфан Миңнуллинның иҗади мирасын саклау һәм үстерү максатыннан, 2014 нче елдан Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты, Мәгариф һәм фән министрлыгы, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры белән берлектә “Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган укытучыларның һәм укучыларның республика конференциясе” оештырыла. Конференциядә катнашучылар 5 номинациядә көч сынаша:

1. **Шигърият. “Сөй гомерне, сөй халыкны...”**
2. **Журналистика. “Кызыл тышлы дәфтәрдән”.**
3. **Драматургия. “Театр яктылыкка, нурга илтә”.**
4. **Фәнни эшләр. “Үзем сайлаган язмыш”.**
5. **Түгәрәк өстәл** (укытучылар өчен)**. “Утырып уйлар уйладым”.**

Гимназиядә Туфан Миңнуллин үзе исән чакта башлап җибәргән күркәм традицияләр бүген дә дәвам итә:

- **Туфан Миңнуллин премиясе**
- **Туфан Миңнуллин беләзеге**

“Туфан Миңнуллин премиясе” айга бер тапкыр фән-мәгариф, сәнгать яки спорт өлкәсендә казанышларга ирешкән, татар телен камил белгән укучыга бирелә. Премия күләме – 1000 сум. Һәр ел чыгарылыш кичәсендә Туфан Миңнуллин исеменнән көмеш беләзекне 11 нче сыйныфны тәмамлаган уку алдынгысына

күренекле драматургның гаиләсе – тормыш иптәше Нәҗибә Ихсанова белән кызы Әлфия Миңнуллина тапшыра.










## ЭКСКУРСИЯ ТЕКСТЫ

**Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган**
**“Хәтер залы” буенча экскурсия тексты**
*(10 минутка исәпләнгән)*

**Укучы 1:** Хәерле көн, кадерле кунаклар! 2013 нче елның 1 нче мартында гимназиябез өчен сөенечле вакыйга - Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган “Хәтер залын” ачу тантанасы булды! Биредә без Туфан абый тормышындагы истәлекле мизгелләргә кайтабыз. Менә аның өстәле, китаплары, алтынга тиң сүзләре...

Туфан абый – җиңелү белмәс көрәшче иде. Аны искә алганда, ирексездән Туфан аганың тормыш девизы булып Тукай сүзләре яңгырый кебек: “Татар бәхте өчен мин җан атармын. Татар бит мин, үзем дә чын татармын!”

**Укучы 1:** “... Әгәр дә мин язучы дигән исемне йөртәм икән, ул сәләт миңа шигъри җанлы, йомшак күңелле әтидән бирелгән; әгәр дә мине җәмәгать эшлеклесе дип атыйлар икән, анысы тормышта тырмашып яшәгән, тынгысыз җанлы әниемнән”, - дип яза Туфан абый истәлекләрендә. Уйлап карасаң, бер Туфан абый Миңнуллин иңнәренә күпме җаваплылык йөкләнгән булган: ул – язучы да, драматург та, туры сүзле депутат та, тугры дус та, сөекле ир солтаны, кайгыртучан әти, бабай да...

**Укучы 2:** Туфан Миңнуллинны драматург буларак аңлар өчен аның “Әлдермештән Әлмәндәр” әсәрен телгә алу да җитә. Баш каһарман – Әлмәндәр Туфан абый кебек һәрчак кешеләргә җылылык бүләк итә, Туган илен ярата һәм үзен туган авылсыз күз алдына да китерә алмый. “Халык һәм Туган җир өчен җавап тотканда – зур көч кирәк. Һәм аны миңа Туган илем, газиз җирем бирә!”- дип әйтә иде автор.

**Укучы 1:** 2012 нче елның 2 нче мае – Туфан аганың бакыйлыкка күчкән көне. Аны озатырга меңнәр килде. Соңгы тапкыр Казан шулай зурлап Тукайны озаткан иде...

**Укучы 2:** Хезмәттәшләре хәтерендә ул һәрвакыт Туфан Абдуллович, тамашачыларга Туфан Миңнуллин, ә без – гимназия укучылары өчен ул Туфан абый булып калачак. Күңелгә якын, көр күңелле, олы җанлы Туфан абый безгә һәр көнне иртән гимназиягә килгәндә хәтер тактасыннан сәлам юллый кебек...

**Зәйнәп:** Сәнгать күгендә патша ул,
Әдиплектә мәшһүр хан,
Милләтем, дип авыз ачса –
Ялкын бөркүче вулкан.
**Мәдинә:**Каһарман итеп күтәрде
Иң гади бәндәләрне.
Гасырларны кичеп яшә,
И милләт Әлмәндәре!

**Укучы 1:** Хөрмәтле кунаклар! Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

**ТЕКСТ ЭКСКУРСИИ**
**по мемориальному залу Туфана Миннуллина**
*(Рассчитано на 10 минут)*

**1 гид:** Добрый день, дорогие гости! Сегодня мы вам расскажем о замечательном человеке, с помощью которого построено это здание нашей гимназии. Туфан Миннуллин – известный татарский писатель, успешный драматург, активный общественный деятель, депутат, еще при жизни удостоившийся многих высоких наград и званий.

**2 гид:** Но не только в этом его духовное величие. Всю жизнь он нес нелегкое бремя защиты интересов родного языка и родной татарской культуры, национальных традиций и истории.

**1 гид:** 1 марта 2012 года в нашей гимназии состоялось открытие мемориального зала Туфана Миннуллина. Вот его книги, письменный стол, памятные фотографии...

**2 гид:** Начиная с 1990 года, Туфан Абдуллович избирался депутатом Верховного Совета Республики Татарстан, многие годы был депутатом Государственного Совета и всегда занимал активную общественную позицию. Но никогда не представлял жизни без родной семьи,родного драматического театра.

**1 гид:** «Люди нашего села», «Мы уходим, вы остаетесь», «Прощайте», «Четыре жениха для Диляфруз» — эти произведения знакомы чуть ли каждому жителю республики. Впрочем, чтобы понять всё творчество Туфана Миннillина-драматурга достаточно упомянуть одно его произведение – «Старик из деревни Альдермыш».

**2 гид:** Главный герой - Альмандар, как и сам Туфан Абдуллович дарил людям тепло, любил Родину и не мог представить себя без любимой деревни. «Когда ты несешь ответ за землю и за народ, который там живет – нужна сила. И её даёт моя Родина, моя земля!», - говорил автор.

**1 гид:** 2 мая 2012 года - день смерти этого выдающегося человека. Проститься с классиком пришли тысячи. В последний раз так Казань провожала самого Тукая…

**2 гид:** Для коллег по парламенту он навсегда останется Туфаном Абдулловичем, для зрителей и почитателей Туфаном Миннуллиным, а для нас, гимназисток, он всегда будет Туфан абый - родной, близкий, живой человек, который каждый день смотрит на нас с мемориальной доски у входа в школу.

**1 гид:** Благодарим за внимание!

# *ЧАРАЛАР*

***(экскурсия текстлары, әңгәмәләр, диспутлар, сценарийлар)***

# 21 нче февраль – Халыкара Туган тел көне

*Автор: Хуҗина Рузилә Тәлгать кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

И туган тел, и матур тел

Әткәм- әнкәмнең теле!

Дөньяда күп нәрсә белдем

Син туган тел аркылы, -

дип җырлаган үзенә газиз тел турында халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай. Бүгенге сөйләшүебез дә туган тел турында булачак.

*Туган оясыннан аерылган кош*

*Канатына мәңге ял тапмый.*

*Туган телен яратмаган кеше,*

*Башкаларның телен яратмый.*

*Халкым теле миңа – хаклык теле.*

*Аннан башка минем телем юк.*

*Илен сөймәс кенә телен сөймәс,*

*Иле юкның гына теле юк.*

Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар, укучылар! Исәнмесез. Без Туган тел бәйрәменә җыелдык. Кунаклар белән таныштыру.

*Бу бәйрәм тарихы белән таныштыру өчен сүзне ..............................бирәбез.*

21 нче февраль - Халыкара Туган тел көне. Бу көнне билгеләп үтү инициативасы белән Бангладеш Республикасы чыга. Анда 1957 нче елның 21нче февралендә, туган телдә белем алу хокукын даулап, биш студент һәлак була. Бу көн 2000 нче елдан башлап ЮНЕСКО карары нигезендә билгеләп үтелә башлады. Хәзер мин сезне ЮНЕСКО Генераль директоры Коитиро Мацуураның “Ана теле бер булыр” дигән мөрәҗәгате белән таныштырып үтәргә телим.

**Ана теле бер булыр**

Көндәлек тормышта без еш кына үзебез сөйләшә торган телне яки телләрне табигый бер нәрсә итеп кабул итәбез. Гаять зур әһәмияткә ия телебез тормыш-көнкүрешебезнең аерылгысыз бер өлеше булып тора. Фикерләү, тәртип һәм үзебезнең тормышыбызның рәвешенә, ысулына әйләнә. Шуңа күрә дә без аның төп функциясен - нәкъ менә **аралашу һәм аңлашу функциясен** онытып җибәрәбез. Туган тел беренче мәртәбә әйләнә- тирә мохитен танып-белергә һәм киңрәк планда дуслар, мәктәп белән аралашуда ярдәм итә торган тел ул. Бу тел - сабыйлык, изге гаилә тәҗрибәсе, башлангыч социаль мөнәсәбәтләр теле.

Дөньяда **6000** нән артык телдә сөйләшәләр. Аларның һәрберсе авазлар, мәгънәләр һәм грамматик кагыйдәләрнең катлаулы системасыннан тора.

Халыкара туган тел көнендә **барлык телләр дә тигез** дәрәҗәдә итеп танылa, чөнки һәр тел кеше халәтенә бердәнбер җавап һәм без сакларга тиеш **тере мирас** булып тора.

Коитиро Мацуура- ЮНЕСКО Генераль директоры.

Шулай итеп, 2000 нче елда Берләшкән Милләтләр Оешмасы, ЮНЕСКО инициативасын хуплап, күптеллелекне яклау йөзеннән 21 нче февральне

“Халыкара туган тел көне” итеп үткәрү турында карар кабул итте.

Берләшкән Милләтләр Оешмасы мәгълүматларына караганда, бүгенге көндә дөньяда 6 меңнән артык телдә сөйләшәләр. Бу телләрнең 95 процентында планетабызның 4 процент кешесе генә аралаша. Аларның кайберләренең хәтта үз язулары да юк. Дөньядагы телләрнең яртысы исә бөтенләй юкка чыгу алдында.

*Аңла, балам...*
*Илләр, телләр, диннәр алмашына –*
*Ниләр көтә адәм баласын?*
*Аңла, балам, сине үзең итеп*
*Туган телең саклап каласын.*

*Куштым сиңа сайлап матур исем –*
*Җисемеңә туры килсен ул.*
*Милләтеңнең бер мирасы итеп,*
*Әткәң - әнкәң биргән исем ул.*

*Вакыт белән бергә үзгәрә бел*
*Телләр өйрән, балам, дөнья күр.*

*Йөз чөермә ләкин үз телеңнән:*
*Бу – Ватанны сату белән бер.*
*Син тугач та, ана сөте белән*
*Иренеңә тамган туган тел.*
*Туган телең җуйсаң, әнкәеңне*
*Онытуың булыр, балам, бел!*

***(С. Әхмәтҗанова.)***

Укучылар, безнең гимназиянең диварларында “татар телендә белем бирүче” дип язылган язулар бар. Гимназиябезнең ныклы терәге, яклаучысы, халык язучысы Туфан ага, гимназиягә килеп кергәндә русча сөйләшкәнне ишетсә, йөзе каралып китә иде. Ә инде татарча аралашкан балаларны күрсә, канәгать елмая, йөзе балкый. Туфан аганы үз телен генә алга куйган дип беребез дә әйтә алмый, чөнки ул, укучылар белән сөйләшкәндә, аның милләтен сорый һәм “үз телеңдә сөйләшә беләсеңме”, дип тә төпченә, ә инде уңай җавап алса, мактап, үсендереп җибәрә иде. Гимназиябездә укучы *таджик кызы Нодира, үзбәк кызы Севара , төрек кызы Сумейра, кыргыз кызы Саулем, әзербәйжан кызы Шола* һ.б. белән әле дә аралаша алса, хөрмәтле Туфан агабыз, һичшиксез, канәгать калыр иде. Әйдәгез аларны тыңлап карыйк.

Мине дә туган телемнең язмышы нык борчый, шуңа да бүген Татарстаныбызның дәүләт теле булган татар теле турында сүз алып барырбыз. Аңа кадәр Фәйрүзәне тыңлыйк әле. “Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә....” Никадәр сыгылмалылык, никадәр байлык шул юлларда.
Хәзерге вакытта бик күпләр татар теле нигә кирәк соң ул? Аны өйрәнү кемгә кирәк? Аның белән кая барып була, диләр. Ә сез ничек уйлыйсыз?

**Укучы.** Мин андыйларга Садри Максуди сүзләре белән җавап бирер идем: “Телебезне өйрәнми башлаган көннән башлап без бетә башлаячакбыз. Безнең бер милләт булып тора алуыбыз телебезне саклый алуыбызга бәйледер. Телебезне саклый алсак, бер милләт булып тора алырбыз, әгәр телебезне саклый алмасак, милләтебездән мәхрүм булырбыз”.

**Укучы** Туфан ага сүзләренә мөрәҗәгать итсәк, ул ”Татар милләте дә гасырлар буена үзен милли йолалары, милли мәдәнияте белән саклап килде. Аның үз әхлакый кануннары бар иде. Аларны без, гәрчә һәр кеше өчен Коръән Кәримдә әхлак нормалары Ходай тарафыннан билгеләнсә дә, язылмаган законнар дип атадык. Ни кызганыч, язылмаган законнарны без оныта яздык.Милләтнең үз йөзе, үз төсмере югала башлады”, - дип язды.

Тагын Туфан абыйга мөрәҗәгать итик әле “Безне бертуктаусыз, рус теле – бөек тел, дип сөйләп торалар. Укый-укый, дөньяда бөек телләр була алмый, үз туган теле һәр милләткә дә бөек, дигән хакыйкатьне аңлатасың. Шул ук бөек дип аталган телдә татардан алынган бихисап сүзләрне күрәсең.

Пушкин теле,
Некрасовның теле
Тургенев һәм Толстой теленең
Тиңсез көч-кодрәтен беләм мин.
Әмма аның башка туган телне
Алыштыруын теләмим.

...Һәр туган тел бөек үзенчә,
Гасырлардан күчкән гасырга,
Саклагыз сез туган телегезне –
Иң зур хәзинә ул асылда.

Әткәй-әнкәй теле сүрелмәсен
Кече халыкларның җанында.
Сорыйм үтенеп, сез саклагыз аны
Җир-ананың изге карынында!

- Татар теле бер дә башкалардан ким тел түгел. Ул дөньядагы дәрәҗәле 14 телнең берсе икән. Татар телен белгән кеше 30 дан артык төрки халык белән җиңел аңлаша һәм аралаша ала.

- Әйе, мин сезнең белән килешәм. Ләкин мин аны туган телем булганга яратам, хөрмәт итәм.

Үз ана телем минем өчен матур, иң тәмле тел,

Үз телем – үз әйберем булган өчен ярата күңел, - дип язган М.Гафури да. Туган телемне бозып сөйләүләренә ачуым чыга. Такташ та минем кебек, телләрне бутап, бозып сөйләүләренә үртәлеп, шаян шигырь язган.

Безнең арабызда ерак илләрдә яшәп тә әти-әнисе, әби-бабасы телен онытмаучылар бар әйдәгез, сүзне аларга бирик.

Туфан абый “Ходай Тәгалә кешеләрне төрле-төрле итеп яраткан. Бүгенге кешеләр шул төрлелектән качарга җыеналар.Мин ышанам – бу галәмәт кешелек дөнҗясының бер чирләп алуы гына. Күп бәргәләнүләр, югалтулар, фаҗигаләр аша кешеләр нәсел-нәсәпләрен эзләп табарга тырышачаклар.Шул исәптән, татарлар да

әби-бабаларының кабер ташларын укыр өчен татар телен өйрәнерләр.Кабер ташлары бер зиратта булса, нәселнең очын табу җиңелрәк булачак.”сак белән Сок” бәете юкка гына иҗат ителмәгән.Әгәр дә ул әллә ничә ел онытылмыйча яши икән – бу безне кисәтеп торучы көчнең тырышлыгы.

Кичәбезне М.Галиев сүзләре белән тәмамлыйсы килә. (Әдилә).

**Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган укытучыларның һәм укучыларның I республика конференциясе җиңүчеләрен бүләкләү тантанасына СЦЕНАРИЙ**

*Автор: Газизуллина Рәмилә Гамил кызы, өстәмә белем педагогы*

**“Без – Туфанлы буын”**

*Сәхнә “Диләфрүзгә дүрт кияү” спектакле декарациясе белән бизәлгән. Җәйге бакча күренеше.“Туган тел” көе яңгырый.*

*4 алып баручы чыга:*

1. ***Энҗе Рәхмәтуллина – Казан шәһәре 12 нче гимназиянең 5 нче сыйныф укучысы;***
2. ***Ильяс Шәйхаттаров – Кама Тамагы урта гомуми белем бирү мәктәбенең 6 нчы сыйныф укучысы;***
3. ***Ландыш Сиражетдинова - Казан шәһәре 12 нче гимназиянең 8 нче сыйныф укучысы;***
4. ***Алмаз Нуруллин – Арча районы Ашытбаш урта мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы.***

**Энҗе һәм Ильяс:** Әссәламегаләйкем!
**Ландыш һәм Алмаз:** Хәерле көн, кадерле кунаклар!
**Энҗе:** Бүген без бар табигатьнең яңарган чорында, язгы ташкыннарның бәргәләнеп-бөтерелеп ирекkә, хакыйкатькә омтылган мәлендә юктан гына бу залга җыелмадык. Бәйрәмебезнең төп сәбәпчесе - бүген 200гә якын татар баласын берләштергән, үз милләтен, туган туфрагын, телен һәм иманын рухи бөеклеккә күтәргән җиңелү белмәс көрәшче, ташкын булып яшәгән Туфан ага!
**Ильяс:** “Мин - бик бәхетле кеше. Ходай миңа бәхетле язмыш биргән. Һәрвакытта яраткан эшем белән шөгыльләндем, юлымда һәрвакыт әйбәт кешеләр булды” дип яза Туфан абый истәлекләрендә. Без - икеләтә бәхетле, Туфан абый. Без дә синең кебек авыл сәхнәләрендә “театр” уйнап үскән малайлар бүген шушы күркәм кичәне алып барабыз.
**Ландыш:** Хөрмәтле тамашачылар, таныш булыгыз: кунак егетләребез - Туфан абыйның якташы, Кама Тамагы мәктәбенең 6 нчы сыйныф укучысы – Ильяс Шәйхаттаров һәм Арча районы Ашытбаш мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы – Алмаз Нуруллин!
**Алмаз:** Һәм... Казан шәһәренең Фатиха Аитова исемендәге 12нче гимназиянең иң сылу кызлары – Ландыш белән Энҗе сезне сәламли!

Татарстан Дәүләт Советы депутаты, халык язучысы Туфан Габдулла улы Миңнуллинның иҗади мирасын тирәнтен өйрәнү һәм популярлаштыру максатыннан үткәрелгән укытучыларның һәм укучыларның I республика конференциясе беркемне дә битараф калдырмады. Сайлап алу этабына 830 гариза килде! Тиздән Конференциядә җиңү яулаган 100 укучының исемнәре игълан ителәчәк.
**Энҗе:** Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган I республика конференциясен гамәлгә ашыручылар:

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты;
- Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы;
- Казан шәһәре Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;
- Г.Тукайның иҗади мирасын саклау һәм үстерү Фонды,
- Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназия.

**Ландыш:** Конференциядә катнашучылар 5 төрле номинациядә көч сынашты. 900ләп фәнни-иҗади эшне республиканың күренекле артистлары, шагыйрьләре, журналистлары, драматурглары һәм галимнәре бәяләде. Алкышлыйк аларны!

*Алмаз белән чиратлашып игълан итәләр:*

**1. Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры артистлары:**
- Нәҗибә Ихсанова;
- Илдус Әхмәтҗанов;
- Әсхәт Хисмәтов;
- Ирек Баһманов;
- Туфан аганың кызы – Әлфия Миңнуллина.

**2. Шагыйрьләр:**
- Ләбиб Лерон;
- Йолдыз Шәрапова;
- Луиза Янсуар.

**3. Журналистлар:**
- Казан федераль университетының гаммәви коммуникацияләр һәм социаль фәннәр Институты профессоры **Васил Гарифуллин;**
- “Сөембикә” журналының әдәби мөхәррире **Эльмира Закирова;**
- “Сәхнә” журналы хәбәрчесе **Рания Юнысова.**

**4. Драматурглар:**
- Рәдиф Сәгъди;
- Данил Салихов.

**5. Казан федераль университетының филология һәм сәнгать Институты галимнәре**:
- Әлфәт Закирҗанов;
- Таһир Гыйләҗев;
- Нурфия Йосыпова;
- Илһам Гомәров;
- Флера Сәйфуллина;
- Әлфия Мотыйгуллина;
- Чулпан Куракова;
- Гөлфия Гайнуллина.

Хөрмәтле жюри әгъзалары, сезгә чиксез рәхмәтебезне белдерәбез!

**Алмаз:** Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган I республика конференциясенең төп иганәчеләре:
- Татарстан Республикасы Дәүләт Советы;
- Казан шәһәре мәгариф идарәсе;
- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

- “Таттелеком” ачык акционерлык җәмгыяте;
- Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма Комитеты;
- “Татарстан китап нәшрияты”;
- Татарстан Язучылар Берлеге;
- “Сөембикә” журналы;
- “Ялкын” журналы.

Бергә һәм бердәм булыйк! Зур рәхмәт сезгә!

**Ландыш:** Тантананы ачу өчен сүз Конференциянең жюри рәисе - Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, халык шагыйре Разил Исмәгыйль улы Вәлиевкә һәм Казан шәһәре мәгариф идарәсе җитәкчесе Илсур Гәрәй улы Һадиуллинга бирелә. Рәхим итегез, хөрмәтле кунаклар!

***Разил Вәлиев һәм Илсур Һадиуллин чыгышлары.***

**Ландыш:** “Театр – чынны ялганнан аерырга өйрәтүче фән үзәге” дигән Туфан ага. Алмаз, син укуны тәмамлагач, тормышыңны театр белән бәйләргә телисең, дип ишеткән идем.
**Алмаз:** Нәкъ шулай! Сәхнә – минем яшәү рәвешем. Без – Ашытбаш укучылары “гастрольләрдән” кайтып кермибез. Күптән түгел “Диләфрүзгә дүрт кияү” спектакле белән бөтен Арча районы авылларында булып кайттык.
**Ландыш:** Туфан абыйның иң рәхәт язылган пьесасы “Диләфрүзгә дүрт кияү” комедиясе булган. Чөнки аны аңарга әтисе белән әнисе язышкан... Хөрмәтле тамашачылар, Конференциянең “Драматургия. Театр яктылыкка, нурга илтә!..” номинациясендә Ашытбаш мәктәбе укучылары уйнаган “Диләфрүзгә дүрт кияү” спектакле 1 урын яулады. Афәрин, Ашытбаш! Йә, Алмаз, сез әзерме?
**Алмаз:** Шәкүр һәрвакыт әзер, Диләфрүз! Хөрмәтле тамашачылар, кәрәзле телефоннарыгызны сүндереп куюыгызны үтенәбез. Без “Диләфрүзгә дүрт кияү” спектаклен башлыйбыз!

***“Диләфрүзгә дүрт кияү” спектакленнән өзек. Арча районы Ашытбаш мәктәбе укучылары. 15 минут.***

**Энже:** 2014 нче елның 21нче февралендә гимназиябездә Конференциянең “Драматургия. Театр яктылыкка, нурга илтә!..” номинациясе буенча Сайлап алу туры үткәрелде. Бирелдә республиканың 12 районыннан һәм Чаллы, Казан шәһәрләреннән 30га якын иҗат коллективлары күренекле драматургның әсәрләрен сәхнәләштерде. 1нче урынга лаек булган иң яхшы спектакльләрне бүген сез дә карый алачаксыз, хөрмәтле тамашачылар!
Ильяс, бу урында “Драматургия” номинациясенең төп иганәчесен дә әйтеп үтәргә кирәктер...
**Ильяс:** Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры. “+ТЕАТР. Тормышыңа театр өстә!”

**Энже:** Камал театры белән хыяллар чынга аша, дияр идем мин! Сайлап алу турында катнашкан һәр укучыга Камал театрыннан истәлекле бүләкләр һәм спектакльләргә билетлар тапшырылды.
Камал театры директоры Илфир Илшат улы Якупов “Драматургия” номинациясендә җиңү яулаган укучыларга тагын бер онытылмаслык бүләк ясамакчы. Иртәгә җиңүчеләребез данлыклы Камал театрына кунакка барачак. Укучыларның хыялын чынга ашырганыгыз өчен зур рәхмәт Сезгә, Илфир әфәнде!
**Ильяс:** Менә бәхетлеләр! Алар бит анда “тере” артистлар белән күзгә-күз очрашачаклар, репетицияләрен күрәчәкләр, баш режиссёр Фәрит абый Бикчәнтәев белән танышачаклар, тагын... ул зур хыял сәхнәсендә “мәтәлчек” атачаклар...
**Энже:** Син бигрәк хыялый икәнсең, Ильяс! Минем тизрәк бәхетлеләр исемлеген беләсем килә. Конференциянең “Драматургия” номинациясендә җиңүчеләрне тәбрикләү өчен Туфан аганың иң якын кешесен, мәшһүр артисткабыз - хөрмәтле Нәҗибә ханым Ихсанованы һәм Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры директоры Илфир Илшат улы Якуповны чакырабыз! Сәхнәгә рәхим итегез, хөрмәтле кунаклар!

***Нәҗибә Ихсанова белән Илфир Якупов чыгышлары.***
***“Драматургия” (сәхнәләштерү) номинациясендә җиңүчеләрне бүләкләү.***

**Музыкаль номер. Латыйпова Зәйнәп башкаруында җыр.**

**Алмаз:** Ильяс, синең пьеса язып караганың бармы?
**Ильяс:** Юк, әлбәттә. Моның өчен бит Туфан абыйныкы кебек сәләт кирәк. Сәхнәдә уйнау миңа күбрәк ошый. “Авыл эте Акбай” спектаклендә Актырнак булганым бар. Вау-вау!
**Алмаз:** Туфан абыйның дәвамчылары үсеп килә, дустым. Конференциягә укучылар иҗат иткән 35 пьеса килде. Аксубай районы Яңа Ибрай мәктәбе укучысы Рузилә Әмирова язган “Өмет” пьесасының сәхнәдә куелышын да күреп соклandык... Шулай итеп, Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган I республика конференциясенең “Драматургия” номинациясендә җиңү яулаган яшь драматургларны бүләкләү өчен сәхнәгә драматурглар – ***Салихов Данил Хабибрахман улын***, ***Сәгъдиев Рәдиф Нәҗип улын һәм Татарстан Республикасы Язучылар Берлеге рәисе урынбасары, шагыйрь Аймәтов Рамис Кыям улын*** чакырабыз! Рәхим итегез!

***“Драматургия” (пьеса) номинациясендә җиңүчеләрне бүләкләү.***

**Туфан Миңнуллин. “Кәрлә – мәктәп баласы”.**
**Катнашалар: Фатиха Аитова исемендәге 12 нче гимназия укучылары. Җитәкчеләре: Насыйбуллина Гөлнур Зәкәрия кызы һәм Хәбибуллина Лилия Дамир кызы.**

***Шигъри-музыкаль композиция.***

*1. “Шигърият. Сөй гомерне, сөй халыкны” номинациясендә җиңүчеләр төрле темага шигырьләрен сөйли.*
*2. Укучылар талгын көйгә Туфан абый турында шигырьләр сөйли.*

**Ландыш:**
Үзең киттең, тик исемең калды,
Шигырьләрдә – синең гомерең.
Без яшибез әле, Туфан абый,
Онытмыйча булган кадерең!

**Алмаз:** Кадерле дуслар, сәхнәдә - Конференциянең “Шигърият. Сөй гомерне, сөй халыкны” номинациясендә 1, 2, 3 нче урыннар яулаган яшь шагыйрьләр! Алкышлыйк аларны!

**Ландыш:** Конференциянең “Шигърият” номинациясенә 400ләп шигырь килде. Жюри әгъзалары шулар арасыннан 30 иң яхшы шигырь авторларын билгеләде. Җиңүчеләрне бүләкләү өчен бирегә Туфан аганың кызын Әлфия ханым Миңнуллинаны һәм хөрмәтле жюри әгъзалары – Ләбиб Лерон, Йолдыз Шәрапова һәм Луиза Янсуарны чакырабыз! Рәхим итегез!

***Әлфия Миңнуллина һәм жюрилар чыгышы.***
***“Шигърият” номинациясендә җиңүчеләрне бүләкләү.***

**Музыкаль номер. “Курайчылар ансамбле”.**

**Энже:** Туфан Миңнуллин – гаҗәеп талант иясе. Ул – ялкынлы публицист, талантлы драматург, туры сүзле депутат, эчкерсез журналист та әле. “Татарстан яшьләре” газетасында 2000 нче еллардан бирле чыгып килгән “Кызыл тышлы дәфтәрдән” сәхифәсе күпме кешене уйланырга һәм Туфан абыйга хат язарга мәҗбүр иткән.

**Ландыш:** Әлбәттә, күп хатлар Туфан абыйга тапшырылмыйча да калгандыр. Әмма бу хатларда – халкыбызның сулышы, яшәеше чагыла. Шундый “тапшырылмаган хатлар”ның берсе Конференциянең “Журналистика. “Кызыл тышлы дәфтәрдән” номинациясенә дә килеп иреште. Аны Кама Тамагы районы Олы Салтык мәктәбе укучысы Гыйзетдинова Альбина юллаган. Бу хатны сезгә бераз кыскартып ул үзе укып китәр. Рәхим ит, Альбина!

**Альбина:**“Исәнмесез, Туфан абый! Хәлләрегез ничек? Сәлам сезгә авылдагы бөтен кешедән. Менә Сезгә хат язарга уйладым әле. Күбрәк Сезнең “Татарстан яшьләре” гәҗитендә басыла торган “Кызыл тышлы дәфтәрне” укыгач, шуңа җавап яза идем. Андагы күп язмаларыгыз үзегезнең Мәрәтхуҗадан алынган бит. Укыйм да, ә бу Исфат абый, бусы Бәртдин, бусы Камәр дип, уйлана идем. “Минһаҗ маҗаралары”н укыган саен укыйсы килә...

Хат язуымның сәбәбен онытып җибәрдем бит. Туфан абый, безнең авылда яшьләр бик күп. Үзебезчә әзерләнеп күрше-тирә авылларда концертлар да куеп йөрибез. Фермада күпме кызларыбыз эшли. Хәзер бит кызлар авылдан китү ягын гына карыйлар. Менә шул кызларыбыз һәм авылда калучы егетләребез турында берәр пьеса яза алмассыз микән? Мәсәлән, сезнең авылыгыз бетеп бара иде бит.

“Үлем белән ике арада” чакта сез ничек булыштыгыз. Әнә хәзер ничек тырышып, берсеннән-берсе уздырып яшәп яталар.

Бик зур рәхмәт сезгә, безне мәктәпле иттегез. Шәһәрләрдә дә мондый мәктәпләр аздыр. Хәтердә, мәктәпнең нигезен салганда Нәҗибә апа да килгән иде, ул да көрәк белән туфрак алып салды... Сез булмасагыз без мондый мәктәптә укый алмаган булыр идек.

Туфан абый, әле күптән түгел без Казанга Сез төзергә булышкан кызлар гимназиясенә кунакка бардык. Бик матур бина икән. Бик кунак иттеләр, барыбызга да бик ошады. Менә бит монда баруның да сәбәпчесе сез. Сезнең аркада кунак булып кайттык.

Дефицит кеше сез Туфан абый. Зур хәреф белән языла торган Кеше. Без сезне мәңге онытмабыз...”

**Энҗе:** “Журналистика” номинациясендә җиңүчеләрне бүләкләү өчен Казан федераль университетының гаммәви коммуникацияләр һәм социаль фәннәр Институты профессоры Васил Заһит улы Гарифуллинны, “Сөембикә” журналының әдәби мөхәррире Эльмира Мизхәт кызы Закированы һәм “Татарстан яшьләре” газетасы урынбасары Атлас Гафиятовны чакырабыз! Рәхим итегез!

***Васил Гарифуллин, Эльмира Закирова, Атлас Гафиятов чыгышлары.***
***“Журналистика” номинациясендә җиңүчеләрне бүләкләү.***

**Туфан Миңнуллин. “Ай булмаса, йолдыз бар”.**
**Катнашалар: Казан шәһәренең 34 нче татар-рус урта мәктәбе укучылары. Җитәкчеләре: Дәминова Ләйсән Миңназыйм кызы һәм Зарипова Гөлнур Гаптелбәр кызы.**

**Алмаз:** Бүген гимназиядә - чын иҗат бәйрәме. Иртәдән бирле Журналистика, Шигърият, Драматургия һәм Фәнни эшләр буенча Остаханәләр эшләде. Укытучылар өчен оештырылган “Түгәрәк өстәл”дә куәтле әңгәмәләр куерды... Туфан Миңнуллинның тормышын һәм иҗатын өйрәнүче укучылар аерым игътибарга лаек. Конференциядә катнашу өчен 300гә якын фәнни-иҗади эш юлланган булса, Фәнни эшләр Остаханәсендә бүген өч төркемдә 52 укучы катнашты. Афәрин!

**Ландыш:** “Фәнни эшләр. “Үзем сайлаган язмыш” номинациясендә җиңү яулаган укучыларны бүләкләү өчен сәхнәгә Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф һәм регионара хезмәттәшлек бүлеге җитәкчесе Алсу Сәмигулла кызы Шәрипованы һәм “Татар китап нәшрияты” директоры Дамир Сабирҗан улы Шакировны чакырабыз! Рәхим итегез, хөрмәтле кунаклар!

***Алсу Шәрипова, Дамир Шакиров чыгышлары.***
***“Фәнни эшләр” номинациясендә җиңүчеләрне бүләкләү.***

**Ландыш:** Туфан ага татар теле һәм әдәбияты укытучыларының яклаучысы, аларның юлларын яктыртучы Маяк иде... Укытучылар өчен уздырылган Түгәрәк өстәлдә бу

фикер кат-кат әйтелде. Хөрмәтле укытучыларыбыз, Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган I республика конференциясе җиңүчеләре – сезнең шәкертләрегез. Бу – сезнең дә җиңүегез! Безнең юлларны яктыртучы Маяк сез! Рәхмәт сезгә!
**Алмаз:** "Түгәрәк өстәл. Утырып уйлар уйладым" номинациясендә җиңү яулаган укытучыларны бүләкләү өчен сәхнәгә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе урынбасары, "Ак калфак" хатын-кызлар оешмасы рәисе – Кадрия Рәис кызы Идрисованы һәм Казан федераль университеты доценты – Әлфәт Мәгъсүмҗан улы Закирҗановны чакырабыз! Рәхим итегез, хөрмәтле кунаклар!

***Идрисова Кадрия Рәис кызы һәм Закирҗанов Әлфәт Мәгъсүмҗан улы чыгышлары.***
***"Түгәрәк өстәл. Утырып уйлар уйладым" номинациясендә җиңүчеләрне бүләкләү.***
***Укытучылар чыгышы.***

**Музыкаль номер: Кытайның "Чишмә" татар авылыннан килгән кунагыбыз – Базарбай Морад улы Бикчәнтәев. Каршы алыгыз!**

**Номер: "Әкият" мода театры.**
*4 алып баручы чыга:*
**Энже:** Хөрмәтле укучылар! Бүгенге кичәне үзегез иҗат иткән шигъри юллар белән тәмамлыйсыбыз килә!
Туфан абый! Бик зур рәхмәт Сезгә,
Сезнең иҗат куәт өстәде.
Сез мәңге яшь, һаман исән әле,
Ишетегез! Туфан ҮЛМӘДЕ!
**Ильяс:**
Без – Туфанлы буын!
Безне уйлап үтте көннәрең.
Иҗатыңны дәвам итәрбез без,
Көтә безне синең үрләрең.
**Ландыш:**
"Мин татар!" дип кычкырасы килә!
Ишетсеннәр иде галәмнәр.
Яңа ачышларга юл саласы,
Башкарасы күпме эшләр бар.
**Алмаз:**
Туфан ага!
Ышан, синең горур исемеңә
Тап төшермәбез без дә беркайчан.
Киләчәгебез якты, ачык булыр.
Татар булып бергә яшәсәк!

**Гимназия хоры "Туган тел" җырын башкара.**

## ПРЕСС-РЕЛИЗ

**Идел бит ул...**

27 мартта – Халыкара театр көнендә Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган II республика конференциясе җиңүчеләре Фатиха Аитова исемендәге 12 нче гимназиядә узган "Идел бит ул..." дип исемләнгән бәйрәм тантанасын тамаша кылды.

Аның иҗаты – Идел кебек киң...

Фикерләре – Идел кебек тирән...

Аның исеме – Идел кебек мәңгелек!..

Бүләкләү тантанасы "Голос. Дети" проекты ярымфиналисты Сәидә Мөхәмәтҗанова башкаруында "Су буйлап" җыры белән башланып китте...

Әлеге конференция беркемне дә битараф калдырмады. Сайлап алу этабында 700дән күбрәк укучы катнашты!

Быел Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган конференция икенче тапкыр уздырылды. Аны гамәлгә ашыручылар:

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты;
- Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы;
- Казан шәһәре Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;
- Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры;
- Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназия.

Конференциядә катнашучылар өч төрле номинациядә көч сынашты. Аларның фәнни-иҗади эшләрен республиканың күренекле сәнгать әһелләре, журналистлары һәм галимнәре бәяләде.

Конференция җиңүчеләрен конференциянең жюри рәисе - Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, халык шагыйре Разил Вәлиев, Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары, мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, Россиянең һәм Татарстанның халык артисткасы Нәҗибә Ихсанова, Казан федераль университетының гаммәви коммуникацияләр һәм социаль фәннәр Институты профессоры Васил Гарифуллин, Туфан аганың кызы – журналист Әлфия Юнысова, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры директоры Илфир Якупов тәбрикләде. Конференциянең 54 җиңүчесенә истәлекле статуэткалар һәм Туфан Миңнуллинга багышланган затлы китаплар тапшырылды.

Бәйрәм тамашасы автор башкаручы, мәхәббәт җырчысы Илназ Сафиуллин, халыкара бәйгеләр лауреатлары Алмаз Әхмәтҗанов, Җәмилә һәм Илдар Габитовлар, "Сәйдәш" бию ансамбле чыгышлары белән үрелеп барды.

Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган бәйрәм – Тау ягының мәгърур Иделе, аның батыр улы турында кыска хикәят булды. Алда әле сүзләр күп булыр... Рәхмәт Сезгә, Туфан ага!

**Конференцияне Оештыру комитеты**

**Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган укытучыларның һәм укучыларның II республика конференциясе җиңүчеләрен бүләкләү тантанасына СЦЕНАРИЙ**

*Автор: Газизуллина Рәмилә Гамил кызы, өстәмә белем бирү педагогы*

## "Идел бит ул..."

- 12 сәгать 40 минутта "Без – Туфан оныклары" дип исемләнгән фильм күрсәтелә башлый. Регламенты – 22 минут.
- 13 сәгать 02 минутта экранда Туфан ага тормышыннан кадрлар, Идел елгасы күренешләре бирелә.
- "Идел бит ул" көенә сәхнә артыннан әйтелә:

"Тау ягының мәгърур Иделе... Үз милләтен, туган туфрагын, телен һәм иманын рухи бөеклеккә күтәреп, әледән-әле бәргәләнеп-бөтерелеп иреккә, хакыйкатькә омтылып ага да ага... Идел бит ул..."

𝄞 ***Сәйдә Мөхәммәтҗанова. "Идел бит ул" татар халык җыры.***

*4 алып баручы чыга:*

5. *Алмаз Сабирҗанов - Г.Камал ис. Татар дәүләт Академия театры артисты;*
6. *Ландыш Сираҗетдинова - 12 гимназиянең 9 сыйныф укучысы;*
7. *Алмаз Нуруллин – КДМСУның театр факультеты студенты.*
8. *Энҗе Рәхмәтуллина – 12 гимназиянең 6 сыйныф укучысы.*

*"Тәфтиләү" көенә:*

**Энҗе:** Аның иҗаты – Идел кебек киң...

**Алмаз Н.:** Фикерләре – Идел кебек тирән...

**Ландыш:** Аның исеме – Идел кебек мәңгелек!..

**Алмаз С.:** Бәйрәмебезне башлар өчен бу олпат шәхеснең исемен телгә алу да җитә – Туфан Габдулла улы Миңнуллин! Туфан ага җиңелү белмәс көрәшче иде. Аның турында искә алганда, әйтерсең лә, Тукай сүзләре яңгырый кебек: "Татар бәхте өчен мин җан атармын. Татар бит мин, үзем дә чын татармын!"

**Ландыш:** Бүген бирегә Туфан ага кебек җиңелү белмәс, үҗәт, күренекле драматургның якты истәлегенә багышланган II республика конференциясендә җиңү яулаган татар кызлары һәм егетләре җыелды.

**Энҗе:** Әлеге конференция беркемне дә битараф калдырмады. Сайлап алу этабында 700дән күбрәк укучы катнашты!

**Алмаз Н.:** Быел Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган конференция икенче тапкыр уздырыла. Аны гамәлгә ашыручылар:

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты;
- Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы;
- Казан шәһәре Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;
- Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры;
- Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназия.

**Алмаз С.:** Тантананы ачу өчен сәхнәгә Россиянең һәм Татарстанның халык артисткасы - Нәҗибә Гыймаделислам кызы Ихсанованы, Конференциянең жюри рәисе - Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, халык шагыйре Разил Исмәгыйль улы Вәлиевне чакырабыз. Рәхим итегез, хөрмәтле кунаклар!

***Нәҗибә Ихсанова, Разил Вәлиев чыгышы.***

**Алмаз Н.:** Алмаз, быел Конференция җиңүчеләренә "Оскар"лар тапшырачаклар, дип ишеткән идем.
**Алмаз С.:** "Оскар"?! Без әлегә Лос-Анджелеста түгел, Алмаз... Ә инде бүләкләргә килгәндә, Конференциянең 54 җиңүчесен истәлекле статуэткалар һәм Туфан Миңнуллинга багышланган затлы китаплар көтә!
**Алмаз Н.:** Болай булгач, без бүләкләрне барлый торыйк. Ә сезне "Сәйдәш" бию ансамбле сәламли!

***"Сәйдәш" бию ансамбле. "Татар бәйрәм биюе".***
***Җитәкчесе: Таһир Латифуллин.***

***I. ФӘННИ ЭШЛӘР.***

**Ландыш:** "Акыллы буласың килсә, акыллы кешеләр белән генә аралаш", дигән Туфан ага. Бүген гимназиядә иртәдән бирле Фәнни эшләр буенча Остаханәләр эшләде. Биредә 2 төркемдә 35 укучы катнашты. Афәрин!
**Алмаз С.:** Бүген укучылар Туфан абыйга бик тә кадерле булган "Туфан Миңнуллин публицистикасы һәм татар милли яңарышы" темасына чыгыш ясады. Милләт мәсьәләсендә, Туфан ага җавабын өздереп әйтә иде: "Минем үз юлым бар: милләт, аның тоткан юлы, ул ничек яши, рухи дөньясы, хәтта хәле, менә шулардан читкә китмим..."
**Ландыш:** Ә мин бераз читкә китеп булса да, шуны өстим. Быел Конференциядә катнашучылар өч төрле номинациядә көч сынашты. Аларның фәнни-иҗади эшләрен республиканың күренекле сәнгать әһелләре, журналистлары һәм галимнәре бәяләде. "Үзем сайлаган язмыш" номинациясенең жюри әгъзалары - Казан федераль университетының филология һәм сәнгать Институты галимнәре. Менә алар:
- Әлфәт Закирҗанов;
- Таһир Гыйләҗев;
- Нурфия Йосыпова;
- Гөлфия Гайнуллина.

**Алмаз С.:** Хөрмәтле галимнәребез! Сезнең иҗат төркеме Туфан Миңнуллин конференциясен оештыруда күрсәткән хезмәтләре өчен “Ихтирам билгесе” белән бүләкләнә. Рәхмәт Сезгә!

“Фәнни эшләр. “Үзем сайлаган язмыш” номинациясендә җиңү яулаган укучыларны бүләкләү өчен сәхнәгә Казан шәһәре мәгариф идарәсе җитәкчесе урынбасары Илнар Рузәл улы Һидиятовны һәм Казан федераль университеты доценты – Әлфәт Мәгъсүмҗан улы Закирҗановны чакырабыз! Рәхим итегез, хөрмәтле кунаклар!

***ТР Мәгариф һәм фән министры Э.Н. Фәттахов чыгышы.***
***“Фәнни эшләр” номинациясендә җиңүчеләрне бүләкләү.***

**Ландыш:** Алмаз абый, мин Туфан абыйны “яшьлек һәм мәхәббәт җырчысы” дияр идем. Ничә яшьтә булса да, үзен һәрчак унсигездә итеп тойган. Менә аның бер робагыен тыңлап карагыз әле:
Карт түгел мин һәм картаймам мәңгегә.
Ышандырып нәрсә әйтим дәлилгә? –
Галиябану әби булмый һичкайчан,
Бабай диеп эндәшмиләр Хәлилгә...
**Алмаз С.:** Әнә, Туфан абый, сиңа да мач китереп, шәп киңәш биргән: кияүгә чыкканда яшең - кызларныкы, акылың әбиләрнеке булсын, Ландыш. Туфан абый Яңа гасыр татар яшьләренең адымнарын хуплаучы, аларның фикердәше, юлбашчысы иде. Кызлар, егетләр, бергә һәм бердәм булыйк! Кадерле Туфан аганың якты хыялы чынга ашсын! Сезнең каршыда - автор-башкаручы, мәхәббәт җырчысы Илназ Сафиуллин!

***Илназ Сафиуллин. “Яңа гасыр татар яшьләре”, “Юллар” җырлары.***

***II. ЖУРНАЛИСТИКА.***
**Алмаз Н.:** Киләчәк юллары, дигәч, бүген дә, иртәгә дә, берсекөнгә дә юлларда йөргән журналистлар искә төште әле. Журналистның ярты гомере юлда уза шул. Энҗе, син алай-болай Юл юлын сайларга уйламыйсыңдыр бит?!
**Энҗе:** Ничек була инде ул “Юл юлы”?!
**Алмаз Н.:** Журналистның ярты гомере юлда узгач, шул Юл юлын сайлаган кеше – журналист була инде.
**Энҗе:** Туфан абый әйтмешли, үзең көлгәндә, миңа да төрт, мин дә көлермен, яме. Безнең гаиләдә бер журналист бар инде, Алмаз. Әниемнең ярты гомере юлда түгел, телестудиядә уза.
**Алмаз Н.:** Туфан Миңнуллин да Юл юлын сайлаган кеше. Ул ялкынлы публицист, талантлы драматург, туры сүзле депутат кына түгел, эчкерсез журналист та әле. “Татарстан яшьләре” газетасында 2000 нче еллардан бирле чыгып килгән “Кызыл тышлы дәфтәрдән” сәхифәсе күпме кешене уйланырга һәм Туфан абыйга хат язарга мәҗбүр иткән.
**Энҗе:** “Кызыл тышлы дәфтәрдән” номинациясендә 300дән күбрәк укучы катнашты. Конференциягә укучылар “Җиңү тәрәзәләре” исеме белән Бөек Җиңүнең 70

еллыгына багышланган эчтәлекле мәкалә-интервьюларын юллады. Бу язмаларда – халкыбызның аянычлы еллары, Җиңүгә омтылган өметләр чагыла...
**Алмаз Н.:** “Кызыл тышлы дәфтәрдән” номинациясенә килгән иҗади эшләрне республикабызның талантлы журналистлары, галимнәре бәяләде. Таныш булыгыз һәм алкышлагыз!

- Казан федераль университетының гаммәви коммуникацияләр һәм социаль фәннәр Институты профессоры **Васил Гарифуллин;**
- “Сөембикә” журналының әдәби мөхәррире **Эльмира Закирова;**
- “Ялкын” журналы журналисты **Ләйсән Фәйзуллина;**
- “Шәһри Казан” газетасы журналисты **Линар Закиров.**

Хөрмәтле журналистларыбыз! Сезнең иҗат төркеме Туфан Миңнуллин конференциясен оештыруда күрсәткән хезмәтләре өчен “Ихтирам билгесе” белән бүләкләнә. Рәхмәт Сезгә!

**Энҗе:** “Журналистика” номинациясендә җиңүчеләрне бүләкләү өчен Казан федераль университетының гаммәви коммуникацияләр һәм социаль фәннәр Институты профессоры Васил Заһит улы Гарифуллинны һәм Туфан аганың кызын – журналист Әлфия ханым Юнысованы чакырабыз! Рәхим итегез!

***Әлфия Юнысова, Васил Гарифуллин чыгышлары.***
***“Журналистика” номинациясендә җиңүчеләрне бүләкләү.***

𝄞 ***Аккордеонда - халыкара бәйгеләр лауреаты Алмаз Әхмәтҗанов.***
***“Алтын Казан” рок-операсыннан өзек.***

***III. ДРАМАТУРГИЯ***

**Алмаз Н.:** “Артист һөнәре профессия түгел, ә диагноз”, дия торган иде Туфан ага. Алмаз абый, сиңа бу диагноз кайчан “ябышты” соң, ә?
**Алмаз С.:** ...

*(“Мәк чәчәге” спектакленә әзерләнә башлаганны күреп):*
**Алмаз Н.:** Абау! Нишлиләр болар?!
**Алмаз С.:** Сөбеханалла! Менә, кара. Артист диагнозы белән яшәүчеләр бер без генә түгел икән! Киттек, әйдә. Комачауламыйк! Без татарлар театр уйнамыйча тора алабыз мени!..

*Фон (Хөрмәтле тамашачылар...)*
**Гран-при ияләре чыгышы.**
**Әмирхан Еники. “Мәк чәчәге”. Вахитов районы 1 нче татар гимназиясенең 7,8 сыйныф укучылары; җитәкчеләре: Хөснетдинова Эльмира Рөстәм кызы, Жиранина Катарина Алексеевна.**

**Алмаз Н.:** Хөрмәтле тамашачылар, без шулай әкрен генә театр дөньясына да килеп кердек. Конференциянең “Драматургия. Театр яктылыкка, нурга илтә!..” номинациясендә сез яңа гына карап үткән Казан шәһәренең 1 нче татар гимназиясе укучылары уйнаган “Мәк чәчәге” спектакле Гран-при яулады. Котлыйбыз сезне!
**Алмаз С.:** Конференциянең “Драматургия” номинациясе буенча Сайлап алу турларында Казан шәһәре һәм Татарстан Республикасы районнары мәктәпләреннән килгән 40 иҗат коллективы Бөек Ватан сугышы чорын тасвирлаган әсәрдән бер өзекне сәхнәләштерде.
**Алмаз Н.:** Катнашучылар чыгышын Туфан аганың иң якын кешеләре – Нәҗибә Ихсанова һәм Әлфия Юнысова, Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары – Венера Шакирова, Фәнис Җиһанша, Алмаз Сабирҗанов, Кәрим Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры артистлары – Нуретдин Нәҗмиев, Гөлназ Нәүмәтова, театр музее җитәкчесе Розалия Чабатова бәяләде. Алмаз абый, “Драматургия” номинациясенең төп иганәчеләрен дә әйтергә кирәктер...
**Алмаз С.:** Галиәсгар Камал һәм Кәрим Тинчурин исемендәге театрлар. Хөрмәтле тамашачылар, шуны онытмагыз: “Театр Билеттан башлана”!
**Алмаз Н.:** Артистлар театр сөюче яшьләр янына буш кул белән килмәде. 26 февральдә Казан шәһәре мәктәпләре укучылары өчен шушы сәхнәдә Тинчурин театры артистлары катнашында М.Мәһдиевнең “Без – кырык беренче ел балалары” спектакле күрсәтелде. Ә 12 мартта Татарстан районнарыннан килгән мәктәп укучылары Камал театрында Зәки Зәйнуллин әсәре буенча иҗат ителгән “Арбалы хатыннар” спектаклен карады.
**Алмаз С.:** Конференцияне Оештыру комитеты ике милли театрыбызны да “Ихтирам билгесе” белән бүләкли. Алкышлар Сезгә!
Конференциянең “Драматургия” номинациясендә җиңүчеләрне тәбрикләү өчен Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры директоры Илфир Илшат улы Якуповны чакырабыз! Сәхнәгә рәхим итегез, хөрмәтле кунаклар!

***Илфир Якупов чыгышы.***
***“Драматургия” номинациясендә җиңүчеләрне бүләкләү.***

***“Сәйдәш” бию ансамбле. “Берлинны алу”.***
***Җитәкчесе: Таһир Латифуллин.***

***Скрипкада – 12 гимназиянең 5 сыйныф укучысы,***
***регионара бәйгеләр лауреаты Җәмилә Габитова. “Ак калфак”, “Эрбет”.***

**Энҗе:**
**Алмаз С.:** Ә хәзер сүзне бәйрәмебезнең хуҗасына – кадерле Туфан агага бирик. Экранда – Туфан аганың 75 яше тулу уңаеннан Мәрәтхуҗа авылында узган юбилей кичәсендә әйтелгән сүзләре яңгырар... Рәхим итегез!
**Ландыш:** Бүген бәйрәмебезгә Кама Тамагыннан үзенең якташлары килгәнне белсә, Туфан абый сабыйларча куаныр иде.

**Алмаз С.:** Һәм алар бүген – биредә! Сәхнәгә Кама Тамагы районы мәгариф идарәсе башлыгы Наил Мәхмүт улы Гомәровны һәм ... чакырабыз! Рәхим итегез, хөрмәтле кунаклар!

***Кама Тамагы кунаклары чыгышы.***

**Ландыш:** Хөрмәтле тамашачылар! Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган бәйрәмебез – татарның сөекле улы, Тау ягының мәгърур Иделе турында кыска хикәят булды. Алда әле сүзләр күп булыр. Рәхмәт Сезгә, Туфан ага!

**Гимназия хоры "Туган тел" җырын башкара.**

**Алмаз С.:** Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган III республика конференциясендә очрашканга кадәр!

**Энҗе:** Хәерле юллар Сезгә!

**Бергә:** Сау булыгыз!

**Туфан Миңнуллин тууына**

**80 ел тулуга багышланган**

**әдәби-иҗади айлык**

# ПЛАНЫ

**октябрь-ноябрь, 2015 ел**

| № | Вакыты | Чаралар | Класс | Урыны |
|---|---|---|---|---|
| **1.** | **11.10.** | Театраль декада | 1-11 | Г.Камал ис. Академия театры |
| **2.** | **21.10.** | “Әкият” татар дәүләт курчак театры буенча экскурсия “Курчаклар сараена сәяхәт” | 10 | “Әкият” татар дәүләт курчак театры |
| **3.** | **27.10.** | Казан театр училищесы студентлары белән очрашу “Пародияләр концерты” | 5-11 | Гимназиянең Актлар залы |
| **4.** | **10.11.** | “Туфан абый дәресләре” Класс сәгатьләре | 1-11 | Гимназия |
| **5.** | **13.11.** | Иң белемле, сәләтле укучыга Туфан абый премиясен тапшыру | 1-11 | Гимназия |
| **6.** | **18.11** | “Бишек җырлары” бәйгесе | 2-11 | Гимназиянең Актлар залы |
| **7.** | **25.11.** | “Апа-сеңел” бәйгесе | 1-11 | Гимназиянең Актлар залы |
| **8.** | **27.11.** | Мемориаль зал белән 1 нче сыйныф укучыларын таныштыру (экскурсия) | 1 | Т.Миңнуллин истәлегенә багышланган мемориаль зал |